БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ҖОМГА
5 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 79 (5879)
Аерым номеры 10 тиен

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ һӘМ ОБОРОНА ИХТИАҖЛАРЫ

СССР Верховный Советы—„Совет Социалистик Республикалар Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы закон“ ны ике палатада да бер тавыштан раслады. Халык вәкилләре, СССР Верховный Советы депутатлары СССР Финанс Халык Комиссары иптәш Зверев доклады буенча фикер алышуларда катнашып, Ватаныбызның оборона ихтиаҗларына 1940 нчы елгы дәүләт бюджетында 57 миллиард сум ассигнование бирү турындагы такдимне аеруча котладылар.

Депутат Делба үзенең речендә болай диде: „Әгәр дә мин Верховный Совет Кызыл Армиянең куәтен ныгытуга средстволар бирүдә саранланмады һәм саранланмас дип әйтсәм, барлык депутатларның бердәм фикрен чагылдырырмын дип уйлыйм. Ватаныбызның дошманнарына каршы сугышларда үзен бетмәс дан белән каплаган куәтле Кызыл Армиянең барлык төрдәге гаскәрләрендә аңа кирәк булган санда техника һәм кораллар булыр. Аның Хасан күле янында һәм Халхин-Гол елгасында булганга караганда да һәм хәтта Карелия бугазында ак фин армиясен җимергеч рәвештә тар-мар иткәндә булганга караганда да күбрәк дәрәҗәдә Ворошиловның дәһшәтле килограммнары белән дошманның кара авызын каплау өчен җитәрлек металы булыр“.

Иптәш Делба Верховный Советның барлык депутатларының фикрен һәм хисен чагылдырды. Бөек совет халкының сөекле баласы булган Кызыл Армия халыкның гаят зур иҗад эшен тайпылышсыз саклый, социалистик дәүләтнең төп интересларын саклый.

Без капиталистик чолганышта яшибез һәм нинди генә көтелмәгән хәлләрне дә тулысынча коралланган хәлдә каршы алырга һәр вакыт хәзер торырга тиешбез. Англиядәге, Франциядәге сугыш уты кабызучылар Советлар Союзын хәзер бара торган икенче империалистик сугышка барлык чаралар белән тартырга, Советлар Союзына каршы сугышка котыртырга маташтылар. Алар безнең Ватаныбызга һөҗүм итү өчен Финляндия территориясендә зур плацдарм төзеделәр. Батыр Кызыл Армия, Финляндиянең җиңелмәслек дип хисапланган „Маннергейм линиясе“ артына яшренгән армиясен тар-мар итте. Кызыл Армия Финляндиядә просто фин гаскәрләре белән генә түгел, бәлки „Финляндия буржуазиясенә барлык төр кораллар белән ярдәм иткән күп кенә илләрдәге, шул исәптән Англиядәге, Франциядәге империалистларның һәм башкаларның берләшкән көчләре белән“ сугышты. (Молотов).

Финляндия белән булган сугышның җиңүле рәвештә төгәлләнүе Кызыл Армиябезнең куәтен, бөтен оборонабызны тагын да ныгыту кирәклеге турында яңадан исебезгә төшерәләр. Безнең Ватаныбызга каршы юнәлдерелгән һәр төрле яңа провокацияләр мөмкинлеге беткәне юк. Совет халкы тынычлык тели. Ләкин провокаторларның һәм сугыш уты кабызучыларның кайсының гына булса да Ватаныбызга һөҗүм итәргә омтылуларының барсына да һәрбер минутта отпор бирү өчен илебезнең тагын да куәтлерәк Кызыл Армиясе, Хәрби Диңгез Флоты булырга тиеш. Куәтле Кызыл Армия—тынычлыкның иң ышанычлы терәге.

Оборона ихтиаҗларына билгеләнгән 57 миллиард сум,—ул Ватаныбызның бәхте турында, социалистик халык хуҗалыгының һәм культураның тагын да чәчәк атуына ирешү өчен тыныч хезмәт итәргә теләүче бөек халкыбызның бәхте турында кайгыртучанлыкның шаһите. Оборона ихтиаҗларына 57 миллиард—ул, яңа пушкалар, тиз очышлы яңа самолетлар, яңа сугыш караблары, куәтле социалистик державабыз өчен кирәкле булган һәр төрле башка оборона средстволары дигән сүз. Оборона ихтиаҗларына дәүләт бюджетыннан быел 57 миллиард сум билгеләнү турындагы хәбәрне һәрбер совет патриоты тирән канәгатьләнү хисе белән каршы ала.

Бурыч, оборонага тотыла торган һәрбер совет сумын иң күп нәтиҗәле итеп файдаланудан гыйбарәт. Промышленность работникларыннан һәм, барыннан да элек, авиация промышленносте, кораллар, сугыш кирәк-яраклары, судиолар төзелеше промышленносте работникларыннан киләчәктә дә ныклы, иҗад эше таләп ителә. Чөнки безнең самолетларыбыз, безнең коралларыбыз, сугыш кирәк-яракларыбыз, безнең корабларыбыз өзлексез яхшыртылырга тиеш. Һичшиксез, Кызыл Армия һәм Кызыл Флот ихтиаҗларына эшләүче заводларның һәм фабрикаларның социалистик ярышы тагын да киңәер.

Совет халкы үзенең Кызыл Армиясен, үзенең Хәрби Диңгез Флотын гаят зур мәхәббәт белән чолгап ала. Ул көчләрне һәм средстволарны кызганмыйча, Кызыл Армиянең бик яхшы коралланган булуы турында, беренче класслы техника белән коралланган булуы турында һәм нинди генә сугышчан бурычларны да үтәргә сәләтле булуы турында кайгырта.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының сугышчылары, командирлары һәм политработниклары халыкның бөек ышанычын аклау өчен барлык көчләрен куялар. Соңгы елларда Ватаныбызның данлыклы тарихына күп кенә героик сәхифәләр язылды. Бу сәхифәләр халкыбызның хәтерендә бер вакытта да югалмаслар. Алар совет кешеләренең батырлыгын, тирән патриотизмын, ныклыгын, энергиясен мәңге күрсәтеп торырлар.

Гражданнар сугышы елларында ярым ач, ярым ялангач булган Кызыл Армия Ватаныбызның бәхтенә һәм бәйсезлегенә, Бөек Октябрь Социалистик революциясе казанышларына һөҗүм иткән ак гвардеецларны һәм интервентларны тәмам тар-мар итте. Хәзерге заман Кызыл Армиясе гражданнар сугышы вактындагы героик традицияләрне бик яхшы итеп саклады гына түгел, бәлки аларны арттырды да. Кызыл Армия сугышчыларының гүзәл мораль сыйфатлары белән бергә кушылган, Кызыл Армиянең һәм халыкның тимердәй бердәмлегенә тапкырланган югары хәрби техника Ватаныбызны җиңелмәслек итә.

Үткәрелгән кампанияләренең тәҗрибәсенә таянып, хәзерге заманның катлаулы сугыш техникасын нык үзләштереп, халык тарафыннан ышанып тапшырылган коралны мәхәббәт белән саклап, сугышчыларыбыз, командирларыбыз һәм политработникларыбыз үзләренең хәрби осталыкларын көннән-көн яхшыртырлар, үзләренең белемнәрен арттырырлар.

Советлар иленең сугышчылары тарафыннан кабул ителә торган изге хәрби ант текстында болай диелә: „Мин хәрби эшне чын күңелдән өйрәнергә, хәрби милекне һәм халык милкен барлык чаралар белән сакларга һәм иң соңгы сулышыма кадәр үз халкыма, үземнең Совет Ватаныма һәм Эшче-Крестьян хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгән булырга ант итәм.

Мин Эшче-Крестьян хөкүмәтенең приказы буенча үз Ватанымны—Совет Социалистик Республикалар Союзын саклауга басарга һәр вакыт хәзер һәм, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сугышчысы булуым сыйфатында, мин дошманнарны тәмам җиңүгә ирешү өчен үземнең канымны һәм тормышымны кызганмыйча Ватанымны батырларча, оста, лаеклы һәм намуслы рәвештә сакларга вагдә бирәм“.

Хәрби антның гади һәм батыр сүзләре Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының батыр сугышчылары, командирлары һәм политработниклары йөрәкләрендә дәрт тудыралар. Тыныч шартларда, Кызыл Армия частьләрендә ныклы өйрәнү барганда, социализм иленең сугышчылары дисциплина өчен көрәшеп, хәрби эшне нык өйрәнеп, үзләренең хәрби белемнәрен өзлексез яхшыртып үзләренең изге антларын үтиләр.

Маркснның бөек көрәштәше Фридрих Энгельс 1845-елны болай диде: „1792 нче елдан 1799 нчы елга кадәр революцион армияләрнең энтузиазмы нинди мөгҗизалар ясаганны искә алыгыз, алар бары тик ИЛЛЮЗИЯ өчен генә, ЯЛГАН ВАТАН өчен генә көрәштеләр, һәм сез иллюзия өчен түгел, бәлки реаль чынбарлык өчен көрәшә торган армиянең никадәр көчле булырга тиешле икәнлеген аңларга тиешсез...“.

Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты бөтен совет халкы тарафыннан һәм бөтен дөнья хезмәт ияләре тарафыннан яратыла торган үзләренең чын Ватаннарын саклыйлар. Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты коралланган кул белән үз халкының интересларын, үзләренең бөек Ватаннарын саклыйлар һәм шуңа күрә дә алар сугыш кырларында шундый зур рухлану белән, шундый зур энергия һәм какшамас батырлык белән көрәштеләр.

Оборона ихтиаҗларына 57 миллиард—ул Ленин - Сталин партиясе җитәкчелегендә яңа тормыш, яңа, коммунистик җәмгыят төзүче бөтен илебезнең, 183 миллионлы бөтен халкыбызның омтылышын һәм теләген чагылдыру дигән сүз.

„Правда“ 4 апрель.

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясендә депутатлар Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән утырышында. А. Грибовский фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясе

СОЮЗ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

3 АПРЕЛЬ, 1940 ЕЛ

3 нче апрельдә, 11 сәгатьтә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының утырышы булды.

Союз Советы председателе иптәш А. А. Андреев председательлек итә.

Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Фикер алышуларда депутатлардан М. С. Гречуха (УССР ның Тарнополь өлкәсе, Бережан округы) һәм И. А. Лихачев (Курск өлкәсе Касторное округы) катнаштылар.

Фикер алышулар беткәннән соң Союз Советы докладчысының—СССР Финанс Халык Комиссары иптәш А. Г. Зверевнең һәм Союз Советының Бюджет Комиссиясенең өстәмә докладчысы депутат К. И. Николаевның йомгаклау сүзләре тыңланды.

Аннары Союз Советы СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын тавышка куюга һәм раслауга күчә.

Союз Советы депутат К. И. Николаевның СССР ның дәүләт бюджеты доходлар һәм расходлар буенча тавышка куярга; Союз бюджетының доходлар өлешен аерым доход чыганаклары буенча, ә расходлар өлешен ассигнованиеләрнең гомуми суммасы буенча тавышка куярга дигән тәкъдимен кабул итә. 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы законны статьялар буенча тавышка куярга. Аннары СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты раслана.

Союз Советы статьялап уку тәртибендә, бер тавыштан, башта статьялап, ә соныннан бөтен килеш, „Совет Социалистик Республикалар Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы закон“ ны раслый.

Шушының белән Союз Советының VI нчы Сессиясенең дүртенче утырышы ябыла.

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

3 АПРЕЛЬ, 1940 ЕЛ

3 нче апрельдә, кич 6 сәгатьтә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Милләтләр Советының дүртенче утырышы булды.

Милләтләр Советы председателе депутат Н. М. Шверник председательлек итә.

Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Фикер алышуларда депутатлардан Г. Ц. Бельгаев (Бурят-Монголия АССР, Еравна округы) һәм В. А. Малышев (Москва өлкәсе Коломна округы) катнаштылар.

Фикер алышулар беткәннән соң Милләтләр Советы докладчысының—СССР Финанс Халык Комиссары иптәш А. Г. Зверевнең һәм өстәмә докладчының—Милләтләр Советының Бюджет Комиссиясе председателе депутат И. С. Хохловның йомгаклау сүзләре тыңлана.

Аннары Милләтләр Советы СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын тавышка куюга һәм раслауга күчә.

Милләтләр Советы И. С. Хохловның СССР ның дәүләт бюджеты доходлар һәм расходлар буенча тавышка куярга; Союз бюджетының доходлар өлешен аерым доход чыганаклары буенча, ә расходлар өлешен ассигнованиеләрнең гомуми суммасы буенча тавышка куярга дигән тәкъдимен кабул итә. 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы законны статьялар буенча тавышка куярга. Аннары СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты раслана.

Милләтләр Советы статьялап уку тәртибендә, бер тавыштан, башта статьялап, ә соныннан бөтен килеш „Совет Социалистик Республикалар Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы закон“ны раслый.

Шушының белән Милләтләр Советы Алтынчы Сессиясенең дүртенче утырышы ябыла.

КЫР ЭШЛӘРЕ БАШЛАНДЫ

ЮТАЗЫ, 4 НЧЕ АПРЕЛЬ. (ТЕЛЕФОН АША ҮЗ ХӘБӘРЧЕБЕЗДӘН). Ютазы районы колхозчылары кыр эшләре башлануны түземсезлек белән көтәләр. Колхозчылар бердәм теләк белән—чәчүне кыска срокта югары сыйфатлы итеп башкару теләге белән сугарылганнар. Чәчүгә хәзерлек эшләре һәрбер колхозда кат-кат тикшерелә. Бу эштә эшче-авыл хәбәрчеләре рейдында катнашучылар зур булышлык күрсәттеләр.

Бүген, районның Тельман исемендәге колхозында һәм „Балан-түбә“, „Көрәшбүләк“, „Кызыл бүләк“ колхозларында тунга сөрелгән участокларны тырмалау эшенә керештеләр.

„Балан-түбә“ колхозы 79 гектар, „Көрәшбүләк“ колхозы 40, „Кызыл бүләк“ 8 һәм Тельман исемендәге колхоз 30 гектар мәйданда тунга сөрелгән җирләрне тырмаладылар. „Көрәшбүләк“ колхозы члены иптәш Шәрифуллин тырмалауның беренче көнендә үк үзенең нормасын 100 процент итеп үтәде. Ул 4 гектар җир тырмалады.

К. Хөсни.

Сталин һәм Молотов иптәшләргә карел-фин халкының котлавы

Москва, Кремль

Иптәш СТАЛИНГА
Иптәш МОЛОТОВКА

Петрозаводск шәһәренең Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турында СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясенең тарихи карарына багышланган митингка җыелган хезмәт ияләре туган юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин, Сезгә, Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотов, Сезгә үзләренең ялкынлы большевистик сәламнәрен җибәрәләр. СССР Верховный Советы Сессиясе карел-фин халкының теләген, аның омтылышын һәм ышанычын чагылдырды. Без халкыбыз турында Сезнең тарафтан өзлексез күрсәтелә торган бөек кайгыртучанлык өчен Сезгә чиксез рәхмәт әйтәбез.

Кешенең кешене эксплоатацияләве юк ителгән Советлар илендә генә милләтләрнең ирекле рәвештә үсүләре принципы тантана итә. Кечкенә халыкларның интересларын бу рәвешчә хөрмәтләү, аларның чәчәк атулары турында аталарча кайгыртучанлык күрсәтү бары тик безнең илдә генә мөмкин. Карелия АССР ны Союзный республика итеп төзү турындагы Закон кабул ителгән көн безнең күп милләтле Совет дәүләте тарихына, карел-фин халкы тарихына данлыклы сәхифә булып керер.

Карел-фин халкы сампо*) турында, бәхет турында йөзләрчә еллар буена хыялланды. Бу хыяллар турында бик күп бәетләр, җырлар, әкиятләр чыгарылды. Безнең бу хыяллар белән рухланган борынгы бабаларыбыз руналар**), калевалалар***) чыгардылар. Карел-фин халкы алар белән хәзердә дә горурлана. Бик күп протестлар һәм восстаниеләр булды, ирекле тигез хокуклы тормыш өчен көрәштә карел-фин халкының күп кенә иң яхшы кешеләре үзләренең тормышларын бирделәр. Ләкин бу восстаниеләр һәм протестлар барсы да патша самодержавиесе тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырылдылар. Бөек Октябрь Социалистик революциясе генә халкыбызны, элекке патша Россиясендәге барлык халыклар кебек үк, ирекле үсү юлына, бәхетле һәм шатлыклы тормыш юлына алып чыкты.

Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы яшәгән 20 ел—ул аның хуҗалыгының, культурасының көчле чәчәк ату еллары. Хәерче, ярлы илдән, царизм колониясеннән Карелия чәчәк атучы Советлар иле булып әверелде. Большевистик партия җитәкчелегендә, халыкларның һәм бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы иптәш Сталин җитәкчелегендә, бөек рус халкының туганнарча ярдәме белән, Ленин-Сталин милли политикасын тайпылышсыз үткәрү нәтиҗәсендә, социалистик төзелешнең барлык өлкәләрендә карел халкы ирешкән уңышлар гаять зур.

Карелияне Союзный республика итеп төзү турындагы тарихи закон карел-фин милләтенең тагын да чәчәк атуына, экономиканың үсүенә, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның чәчәк атуына хезмәт итәр. Сталин Конституциясе кояшы белән җылытылган бу закон,—Ленин-Сталин милли политикасының яңа гүзәл җиңүе, социалистик дәүләтебезнең куәтен ныгыту эшендә яңа адым.

Кардәш союзный республикалар семьясендә яңа—уникенче республика төзелде. Балтык диңгезеннән Ак диңгезгә кадәрге киң территориягә урнашкан халкыбыз тарихында яңа матур сәхифә ачылды.

Карел-фин халкының тантанасы гаять зур. Сезгә үзебезнең тирән рәхмәтебезне белдерү өчен сүзләр таба алмыйбыз. Карелияне Союзный республика итеп төзү турындагы закон йөрәкләребезне тиңдәшсез шатлык хисе белән тутыра, безгә яңа көчләр бирә. Без, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы бөек Советлар Союзында алдынгы республикалар сафында булсын өчен үз-үзебезне аямыйча көрәшербез дип Сезне ышандырабыз.

Ватаныбыз тарихи көннәрне кичерә. Кызыл Армия һәм Кызыл Флот Финляндия белән булган сугышта фин армиясен һәм шуның белән бергә Советлар Союзына аеруча дошман булган күп кенә капиталистик илләрнең берләшкән көчләрен тар-мар иттеләр. Төньяк-көнбатыш чикләребездә сугышның иң куркынычлы учагы бетерелде. Кызыл Армиябезнең бу героик җиңүләре, туганыбыз бөек Сталин җитәкчелегендәге халыкның, хөкүмәтенә Сталинның иң турылыклы көрәштәше иптәш Молотов җитәкчелек итә торган куәтле социалистик держава халкының, мондый халыкның җиңелмәслеген бөтен дөньяга тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәштә карел-фин халкы данлыклы Кызыл Армиябезгә зур булышлык итте. Без Сезне, Советлар иленең оборона куәтен киләчәктә дә тайпылышсыз ныгытырбыз дип ышандырабыз. Карел-Фин ССР бөек социалистик державаның төньяк-көнбатыш чикләрендә җиңелмәслек куәтле форпосты булыр.

Яшәсен СССР халыкларының дуслыгы!

Яшәсен безнең туган Совет хөкүмәте һәм аның башлыгы иптәш Молотов!

Яшәсен Ленин-Сталин партиясе!

Яшәсен атабыз, юлбашчыбыз һәм остазыбыз бөек Сталин!

(1940 нчы елның 1 нче апрелендә Петрозаводск шәһәре хезмәт ияләре митингысында кабул ителде. 30 мең кеше катнашты).

*) сампо—икмәк турында йөзләрчә еллар буена килгән хыялны чагылдыра торган халык образы.
**) руна—җыр.
***) калевала—карел-фин халкы эпосы.

Кызыл Армиянең куәте турында Швеция „добровольцлары“

СТОКҺОЛЬМ, 3 апрель. (ТАСС). Стокһольмга Финляндиядә булган Швеция „добровольцлар“ының беренче партиясе кайтты. Алар буржуаз матбугатның Кызыл Армия турындагы ялганнарын фаш итәләр. Аерым алганда Швеция армиясе лейтенанты, очучы „доброволец“ Ренгт Свратцның белдерүе кызыклы. Бу белдерү Кальмарда чыга торган „Кальмартиднинген барометерн“ дигән провинциональ консерватив газетада басылып чыкты.

Лейтенант болай дип яза:

„Мин барыннан да элек бер ел буена Хельсинкида хәрби атташе ярдәмчесе булганлыгымны белдерергә тиешмен. Шуңа күрә дә мин Финляндиядәге шартларны шактый яхшы беләм. Мин, рус самолетларының безнең самолетларга караганда тиз очышлырак икәнлекләрен икрар итәргә тиешмен. Финляндия истребительләре русларның хәзерге заман бомбардировщиклары шикелле тизлек белән күтәрелә алмадылар. Рус очучылары броня белән сакланганнар һәм билгеле, мондый шартларда аларга тидерү җиңел түгел иде. Русларның зенит артиллериясе бар, ул зур тизлек белән һәм зур югарылыкка ата. Аларның тиз ата торган пулеметлары бар. Русларның оборонасы бик яхшы иде. Гаскәрләр бик яхшы коралландырылганнар. Рус очучылары чиктән тыш тәҗрибәле. Авиация—русларның сөекле баласы“.

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ ТӨЗЕЛҮ ТАРИХЫ

(1917—1920 нче еллар)

Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, рус пролетариаты ярдәме белән, татар халкы 1920 нче елның 25 нче июнендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзеде.

Татарстан АССР В. И. Ленин һәм И. В. Сталин инициативасы буенча һәм турыдан-туры алар җитәкчелегендә төзелде.

Татарстан АССР 20 ел эчендә хуҗалык һәм культура төзелешенең барлык өлкәләрендә гаять зур уңышларга иреште. Татарстан хезмәт ияләре массасы бу уңышларны татар халкын яңадан капитализм коллыгына бирергә маташкан буржуаз милләтчеләргә, троцкичы-бухаринчы шпионнарга һәм диверсантларга каршы рәхимсез көрәштә яулап алды.

* * *

1917 нче елгы буржуаз-демократик февраль революциясеннән соң күп милләтле Россиядәге 170 миллион халыкның 70 миллионы великоруслар, ә 100 миллионы рустан башка милләтләр иде, алар изелгәннәр һәм хокуксызлар иде.

Халыклар төрмәсе булган патша Россиясендә йөз еллар буена яшәп килгән милли изү буржуаз демократик революциядән соң да бетмәде. Вакытлы хөкүмәт окраиналарда дәүләт аппаратын ныгыта һәм милли изүне аеруча тупас формада көчәйтә башлады. Барлык халыклар өчен дәүләт теле булып—рус теле, дәүләт мәктәбе булып—шул ук рус мәктәбе калды, окраиналардагы уку йортларында ана телендә укытырга рөхсәт бирелмәде.

Шулай итеп, самодержавие строен бетерү һәм буржузия властен урнаштыру милли изүне бетерүгә китермәде һәм китерә дә алмады. „Милли изүнең иске тупас формасы изүнең яңа, нечкәртелгән, ләкин аның каравы тагын да куркынычрак формасы белән алмашынды“. (Сталин. „Марксизм һәм милли - колониаль мәсьәлә“, 83 нче бит).

Февраль революциясеннән соң окраиналарда буржуаз-азатлык хәрәкәте башланды. Хәрәкәтнең башында милли буржуаз-демократик интеллигенция барды. Буржуаз-демократик февраль революциясе алдыннан татар буржуазиясе хезмәт ияләренә караганда оешканрак иде. Окраиналарда „гомуми милли“ институтлар төзелә башлады. Урта Волгада „милли совет“ төзелде.

1917 нче елның 7 нче мартында татар буржуазиясе Казанда, шәһәр театр бинасында митинг үткәрә, анда мөселман комитеты сайлана. Шул ук вакытта Петрбургда 4 нче дәүләт думасының элекке мөселман фракциясеннән бөтен Россиядәге мөселманнарның үзәк бюросы оештырыла. Үзәк бюро мөселманнарның гомуми беренче Бөтенроссия съездын чакыруга хәзерлек эшләрен җәелдерә.

Мөселманнарның беренче Бөтенроссия съезды 1—11 нче майда, Москвада булды. Съездда 900 гә якын делегат катнашты. Алар, башлыча, Россиядәге барлык мөселман буржуазиясенең, кулакларның һәм муллаларның вәкилләре иде. Мөселманнарның беренче Бөтенроссия съезды бөтен Россия Үзәк Шурасын (Россиядәге мөселманнарның Бөтенроссия советын) сайлады. Үзәк Шура башкарма комитет сайлады.

Беренче съезддан соң урыннарда милли институтлар төзелә башлады. Татар буржуазиясе Казанда Милли Шура (милли совет) оештырды.

1917 нче елның июнь-июль айларында Россия мөселманнарының үзәк шурасы, милли шура белән берлектә, икенче съездны чакыру буенча хәзерлек эше алып бара. 21 нче июльдән 2 нче августка кадәр Казанда Россия мөселманнарының икенче Бөтенроссия съезды үткәрелә. Шул ук вакытта (17 нче июльдә) Казанда мөселманнарның беренче Бөтенроссия хәрби съезды һәм руханиларның беренче Бөтенроссия съезды ачылды. Татар буржуазиясенең инициативасы белән өч съездның утырышларын берләштерергә карар бирелә. 1917 нче елның 22 нче июлендәге берләштерелгән утырышта, тантаналы шартларда, мөселманнарның культуралы - милли автономиясе турында карар кабул ителә. Бу карарны үтәү өчен „культуралы милли автономия коллегиясе“ төзелә. Аның председателе итеп буржуаз-милләтче кадет Садри Максуди сайлана.

Февраль революциясеннән соң татар буржуазиясе, „Үз“ дәүләтен урнаштыру һәм пантюркизм идеясен тормышка ашыру исәбе белән, көнчыгышта яшәүче күп кенә мөселман халыкларын: башкыртларны, кыргызларны һәм башкаларны үз тәэсире астында берләштерү турында хыялый план төзи.

Мөселманнарның беренче Бөтенроссия съездында Азербәйҗан, Төркстан, Башкыртстан буржуазиясе һәм башка окраиналарның буржуазиясе татар буржуазиясенә каршы чыкты. Алар, унитаристларга каршы килеп, территориаль-федератив нигезләрдә дәүләт строе төзүне таләп итәргә керештеләр. Бу съездда федералистлар җиңделәр.

Федератив төзелеш вәкилләре яш милли-промышленность буржуазиясе интересларын яклаучылар булдылар. Бу хәрәкәттә Азербәйҗан һәм Башкыртстан милли буржуазиясе җитәкче роль уйнады. Милли федералистлар да, унитаристлар да, киңәеп бара торган рус революциясеннән зур куркуга төштеләр.

Дәүләт төзелешенең нинди булырга тиешлеге турында татар һәм башкырт буржуазиясе арасындагы каршылык февраль революциясенең беренче көннәреннән үк үсә башлады. Мәсәлән, 1917 нче елның 27 нче апрелендә Уфада мөселманнарның губерна съезды булды. Бу съездда татар буржуазиясе, үз интеллигенциясе белән берлектә, „культуралы - милли автономия“ төзү турында Вакытлы хөкүмәт алдына таләпләр кую буенча карар кабул итүгә ирешә. Ләкин мөселманнарның беренче Бөтенроссия съездында татар буржуазиясе җиңелгәнлектән башкырт буржуазиясе июль башларында Оренбургда „Башкырт халкы союзы бюросы“н оештырды. Бу бюро июль урталарында Оренбургда бөтен Башкыртстан съездын чакыра. Бу съездда башкырт буржуазиясе „Башкыртстан башкыртлар өчен“ дигән лозунг куя һәм территориаль автономия төзү турында карар кабул ителә. Татар һәм башкырт буржуазиясе арасындагы бу каршылыклар мөселманнарның икенче Бөтенроссия съездында аеруча үстеләр. Бу съездда татарларның эре буржуазиясе күпчелек була, шунлыктан культуралы-милли автономия турындагы карар кабул ителә.

Мөселманнарның беренче Бөтенроссия хәрби съездында татар офицерларыннан Бөтенроссия хәрби шурасы сайлана. Татар буржуазиясе милли полклар төзү турында карар кабул итә.

Съездан соң хәрби шура (хәрби совет) төзелә.

Берләштерелгән 3 съездның утырышларыннан соң Көнчыгыш буржуазиясе милли учреждениеләр төзү эшен тагын да киңрәк җәелдерә. Аларда милли буржуазия үзенең көчләрен туплау эшен алып бара. Вакытлы хөкүмәт яшәгән чакта милли буржуазиянең бу оешмалары Вакытлы хөкүмәткә каршы ачыктан-ачык чыга алмадылар.

„Царизмның бетүе һәм Милюков—Керенский хөкүмәтенең сәхнәгә менүе бу ямсез картинага һичбер төрле яхшыртулар кертмәде. Табигый ки, окраиналардагы „гомуми-милли“ институтлар мөстәкыйль дәүләт булып әверелергә тенденция күрсәткәнлектән, алар Россиянең империалистик хөкүмәтенең бик көчле каршылыгына очрадылар“. (Сталин. „Марксизм һәм милли-колониаль мәсьәлә“, 84 нче бит).

Аерым рәвештә һәрбер милли буржуазия „үз халкын“ азат итүгә түгел, бәлки, киресенчә, үзенең сыйнфи өстенлеген урнаштыруга һәм хезмәт ияләре массасын эксплоатацияләүгә омтылды. Үзенең өстенлеген урнаштыру өчен ул милли дошманлыкны көчәйтте. „Окраиналардагы хөкүмәтләрнең“ көрәше—буржуаз контрреволюциянең социализмга каршы көрәше булды һәм шулай булып кала да. Милли флаг тик милли буржуазиянең контрреволюцион ниятләрен томалау өчен уңайлы булган популяр флаг сыйфатында, массаларны алдау өчен генә эшкә юрмәп куела“. (Сталин. „Марксизм һәм милли-колониаль мәсьәлә“, 87 бит).

Татар буржуазиясе үзенең сыйнфи теләкләрен күздә тотып татар хезмәт ияләрен изүне көчәйтте, шунлыктан хезмәт ияләре буржуазиягә кискен протест белдерделәр. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендәге Татарстан хезмәт ияләре, бер үк вакытта рус буржуазиясенә дә, „үзенең“ милли буржуазиясенә дә каршы чыгып, сыйнфи көрәш алып барды. Шуңа күрә дә буржуаз институтлар, иптәш Сталин күрсәткәнчә, „чәчәк атып өлгерә алмыйча, чәчәкләрен коя башладылар“.

* * *

Буржуаз - демократик февраль революциясе Россиянең үзәгендә булган элекке Казан губернасының киң хезмәт ияләре массасын көрәшкә күтәрде.

1—2 нче мартта Казандагы эшчеләр сыйнфы, хезмәт ияләре массасы белән берлектә, переворот ясады.

2 нче мартта эшче депутатлары Советы төзелде. 14 нче мартта ул солдат депутатлары Советы белән бергә кушылды. Казан губернасында крестьян депутатлары Советы бераз соңрак төзелде, ул 1917 нче елның 8 нче маенда Казан губернасы крестьян депутатларының беренче съездында эшче һәм солдат депутатлары Советы белән бергә кушылды.

Эшче, солдат һәм крестьян депутатларының күп кенә Советларында баштарак меньшевиклар һәм эсерлар күпчелек алып торалар иде.

Буржуаз - демократик февраль революциясеннән соң, буржуаз-демократик революцияне социалистик революциягә әйләндерү өчен көрәшкә эшчеләр сыйнфын һәм ярлы крестьяннәрне оештыру бурычы большевиклар партиясе алдында төп политик бурыч булып торды.

Казанда һәм Казан губернасында Бөек Октябрь Социалистик революциясе һәм аны хәзерләү эше РКП(б) Үзәк Комитеты һәм большевикларның Казан оешмасы җитәкчелегендә алып барылды. Бөтен дөнья империалистик сугышы елларында Казандагы большевистик оешма нигездә тар-мар ителгән иде.

Буржуаз - демократик февраль революциясе башланганда Казанда һәм Казан губернасында большевикларның кечерәк аерым группалары гына яшиләр иде. Бу большевистик группалар Казандагы эре предприятиеләр янында булдылар. Казандагы большевистик оешма, бөтен Россиядәге кебек үк, 1917 нче елның март-апрель айларында үсте. Апрель Конференциясе вактында Казанда 400 член бар иде.

1917 нче елны март аенда Казан большевиклары подпольедән чыктылар һәм партиянең Казан Комитетына сайлауларга хәзерлек эше алып бара башладылар.

1917 нче елның 26 нчы мартында 16 кеше составында партиянең Казан Комитеты сайланды. Партия Комитетының председателе итеп В. А. Тихомирнов сайланды. Ул большевикларның Казан оешмасына 4 айга якын—1917 нче елның июль уртасына кадәр җитәкчелек итте.

28 нче мартта партиянең Казан Комитеты большевистик „Рабочий“ газетасын чыгарырга карар бирде. 31 нче мартта „Рабочий“ газетасының беренче номеры чыкты.

Партиянең Казан Комитеты җитәкчелегендә „Рабочий“ газетасы политик армия төзү өчен, социалистик революция хәзерләү өчен зур эш җәелдерде.

Икенче апрельдә партиянең Казан Комитеты район комитетлары оештыру турында карар кабул итте. Алар апрель башларында төзелделәр. Партиянең район комитетларын төзегәннән соң большевиклар партиясе Казандагы хезмәт ияләре массасы арасында зур эш җәелдерде. 22 нче апрельдә большевикларның Казан оешмасы партиянең VII нче Бөтенроссия Апрель Конференциясенә Абрам Комлев һәм Иван Волков иптәшләрне делегат итеп җибәрде.

1917 нче елның 21 нче маенда Казанда большевиклар партиясенең гомуми шәһәр конференциясе булды. Бу конференция, Бөтенроссия Апрель Конференциясе карарларыннан чыгып, буржуаз-демократик революцияне социалистик революциягә үстерү буенча практик чаралар билгеләде.

Нак шул ук вакытта вак-буржуаз мөселман социалистик комитеты эшчеләр сыйнфының татарлардан торган өлеше арасында кызу эш алып барды.

1917 нче елның 7 нче апрелендә, татарларның Алафузов район конференциясендә, татар революционеры Мулланур Вахитов инициативасы белән мөселманнарның социалистик комитеты төзелде. Мулланур Вахитов һәм мөселманнарның социалистик комитеты беренче көннәрдән үк татарлар арасында социалистик идеяләрне пропагандалау буенча зур эш үткәрделәр.

14 нче майда мөселманнарның социалистик комитеты, татарлар өчен клуб ачты, анда көтепханә һәм уку залы бар иде. Аннары эшчеләр театры һәм иҗтимагый фәннәр курслары ачылды. 1917 нче елның июнендә, Мулланур Вахитов инициативасы белән „Кызыл Байрак“ газетасы чыга башлады.

Газетаның 15 нче июньдә чыккан номерындагы баш мәкаләдә Мулланур Вахитов болай дип язды: „Хәзерге вакытта безнең таләпләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) бөтен властьны эшче һәм крестьян Советларына күчерү; 2) тизлек белән бөтен җирне крестьяннәргә бирү; 3) дәүләт думасын һәм дәүләт советын таратү; 4) икенче хөкүмәтнең барлык яшерен договорларын игълан итү һәм Россия халыклары өчен аларның мәҗбүри булмавы; 5) тизлек белән сугышны туктату; 6) барлык заводларны һәм фабрикаларны эшчеләр һәм барлык хезмәт ияләре милке дип игълан итү“.

С. Рогожин.

(Дәвамы бар).

Казан Дәүләт Университетының Сталин исемендәге стипендиягә кандидат отличник—студентлар. Рәсемдә: сулдан—физика - математика факультетының 5 нче курс студенты—комсомолец Г. Краснов һәм химия факультетының 2 нче курс студенткасы А. Атласкина иптәшләр.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

БОЛЬШЕВИК СЕРГЕЙ ЛАЗО

Сергей Лазо—милләте ягыннан бессарабияле—1894 нче елны, Кишенев губернасының Пиатри авылында туган. Аның революцион эше империалистик сугыш чорында башланды. Ул хәрби училищене тәмам итте. Аны фронтка җибәрмәделәр. Училище начальниклары аны „патриотик настроениедә булмаган демократ офицер“ дип характерладылар, мондый кешене хәрәкәт итүче армиягә җибәрү куркыныч иде. Егерме ике яшьлек прапорщик Сергей Лазо Красноярскида торучы 15 нче Себер укчылар полгына җибәрелде.

Красноярскида Сергей Лазо политик сөргенчеләр белән бик тиз элемтә урнаштырды һәм революцион эшкә керешге. Империалистик сугышны гражданнар сугышына әйләндерү турында большевистик лозунг Лазо өчен хәрәкәткә кулланма булып әверелде. Революцион эш анарда чиксез энергия чыганагын кузгатты. Ул көннәрдә Лазо үзенең көндәлегенә болай дип язды:

„Эш һәм эш... сөекле эшкә үзең бөтен көчләреңне корбан итү генә түгел, бәлки аның өчен тормышыңны бирүдән дә курыкмыйсың“.

1917 нче ел. Красноярскида солдатлар һәм эшчеләр массасы арасында аруны белмәүче пропагандист һәм агитатор булган Сергей Лазоның исме, Себер һәм Ерак Көнчыгыш хезмәт ияләренә киң күләмдә билгеле булып әверелә.

1917 нче елның 5 нче мартында эшче һәм солдат депутатларының Красноярск Советының беренче утырышы ачылды, бу утырышта большевиклар алдынгы роль уйнадылар. Меньшевикларның һәм эсерларның Красноярскидагы контрреволюцион оешмалары Советның эшен өзәргә омтылдылар.

Ачык йөзле һәм шат күңелле Сергей Лазо бу көнне үз полгының 4 нче ротасын тулы сугышчан тәртиптә Совет бинасына алып килде. Ул солдатлар исменнән, ротаның үзен Совет карамагына биргәнлеген белдерде. Красноярск Советы Сергей Лазоны солдатлар секциясенә җитәкче итеп куйды.

Күп тә үтми Иркутскидан җәза отряды—ике рота пехота һәм бер артиллерия взводы большевистик Красноярскига каршы җибәрелә. Лазо җитәкчелегендә солдатлар җәза отрядын вокзалда каршы алдылар. Сергей Лазо монда үзенең бик яхшы оратор һәм агитатор икәнлеген күрсәтте. Ул Иркутск солдатларына Советлар турында, большевиклар турында дөресен сөйләде һәм отряд большевикларга каршы чыгудан баш тартты.

1917 нче елның октябрь көннәрендә Лазо Красноярск шәһәрендә хөкүмәт учреждениеләрен басып алуга җитәкчелек итте.

1917 нче елның декабрендә Иркутскидагы контрреволюцион көчләр баш күтәрделәр. Красноярск эшчеләреннән һәм солдатларыннан төзелгән отрядка җитәкчелек иткәне хәлдә Лазо, баш күтәрүчеләргә каршы көрәшү өчен Иркутскига килде.

Хәрби-революцион комитет Лазога юнкерларның контрреволюцион чыгышларын бастыруны тапшырды. Лазо үзенең хәрби оештыручанлык, командирлык һәм политработниклык сәләтләрен киң җәелдерде. Отрядлар төзү белән ул эшчеләрне, шахтерларны хәрби эшне белүче солдатлар-фронтовиклар белән берләштерде. Лазо сугышчыларны үз үрнәге белән рухландырып, көннәрен һәм төннәрен ут линиясендә үткәрде.

1918 нче елның февралендә Иркутскида Советларның II нче Бөтенсебер съезды булды. Читадан съезд адресына тревогалы телеграммалар алынды. Контрреволюциягә каршы ашыгыч рәвештә көрәш оештырырга кирәк иде, Сергей Лазо (ул чагында аңа 24 яш иде) Забайкалье фронтына командующий итеп билгеләнә. Шунда ук ул большевиклар партиясенә керә. Забайкалье шахтерлары һәм крестьяннәре, фронттагы казаклар, Совет властеның дошманнарына кискен нәфрәт белдереп, кызыл отрядлар сафларына керделәр.

Андриановка станциясе фронтны оештыру үзәге булып әверелде. Лазо ашыгыч рәвештә отрядлар һәм полклар оештырды, комиссарлар һәм политработниклар билгеләде. Забайкалье фронты казакларының съезды чакырылды, Советлар ягына чыккан 1 нче Аргун кавалерия полгы үзгәртеп корылды. Аргунчылар халыкка карата: „Бер генә сәгаткә дә кичекмичә Аргун полгына керегез, бу полк революция байрагын югары тотты һәм югары тотар... Бөтен власть Советларга!“ дип өндәмә чыгардылар.

1918 нче елның җәендә Семенов бандаларына каршы Лазо уңышлы көрәш алып барды. Семеновның яхшы коралланган офицер частьләре кызылларның һөҗүме астында чигенделәр.

1918 нче елның көзендә Себердә һәм Ерак Көнчыгышта хәлләр тагын да кискенләште. Владивостокка интервентларның йөз меңле армиясе төшерелде. Чехлар Забайкальедә хәрәкәт иттеләр. Советлар Россиясе белән элемтә өзелде. Советлар Забайкальесе һәм Амур өлкәсе территориясенең бер өлеше дошманнар боҗрасы эчендә калды. Манжуриядә Семенов бандалары тагын кыймылдый башладылар.

Лазо ашыгыч рәвештә Байкал буе фронтына җибәрелде. Фронтны тоткарлау мөмкин түгел иде инде. Сергей Лазо, кызыл отрядларны, партия һәм совет оешмаларын эвакуацияләүгә мөмкинлек бирү өчен, чехларның һөҗүменә тоткарлык ясарга карар бирде. Чигенү һәм эвакуацияләү ике бронепоезд һәм Лазо җитәкчелегендәге кызыл гвардеецлар отрядлары ярдәме белән алып барылды. Бронепоездлар дошманның һөҗүм итү юлларында киртәләр ясап, күперләрне шартлаттылар.

Себердә адмирал Колчак, Забайкальедә атаман Семенов, Амур өлкәсендә һәм Приамурьедә атаманнар Кузнецов һәм Калмыков властьны кулга алдылар, Владивостокта япон империалистларының һәм Колчакның ялчысы генерал Розанов хөкем сөрде. Коммунистларны, революцион эшчеләрне һәм крестьяннәрне үтерү һәм җәзалау башланды. Урта гасырдагыча газаплау төрмәләре оештырылды. Ак гвардеецлар барлык көчләре белән Лазоны эзләделәр. Аны тоткан өчен алтын белән ун меңнәрчә сум акча вәгдә ителгән иде.

Ләкин Лазоны тота алмадылар. Эшчеләр, тимер юлчылар һәм крестьяннәр, үлемнән дә курыкмыйча, Лазоны яшерделәр. Алар Лазога Амур өлкәсеннән Владивостокка барырга ярдәм иттеләр. Монда башка иптәшләре белән берлектә, Сергей Лазо, ак гвардеецлар тарафыннан туздырылган яшрен партия оешмасының эшен юлга салды.

1919 нчы елның язында Себердә һәм Ерак Көнчыгышта партизанлык хәрәкәте киң җәелде. Ерак Көнчыгыш һәм Себер партия оешмаларының Владивостокта чакырылган конференциясе, партизанлык хәрәкәтенә җитәкчелек итү турында карар кабул итте. Сергей Лазо Приморьедәге партизанлык көчләренең командующие булып әверелде.

Лазо һәр кайда булырга өлгерде, ул кызыл партизаннарны сугыш эшенә өйрәтү занятиеләрендә дә, тайгадагы лазаретта да, сугышның аеруча куркынычлы участкыларында да булды.

Партизанлык хәрәкәтен бер нинди репрессияләр һәм ерткычлыклар да бетерә алмадылар. Япон интервентлары иртәдән төнгә кадәр тайгада эзләнделәр, ләкин берәүне дә таба алмадылар.

Бу вакытта Советлар Россиясендә дә хәлләр үзгәрде. Антантаның ике походы җимерелде. Колчакчыларның калдыклары таркалды. 1919 нчы елның декабрендә Владивостокта булган партия конференциясе восстание оештырырга, Кызыл Армия килгәнче үк инде интервентлар һәм ак гвардеецлар властен бәреп төшерергә карар бирде. Лазо партия комитетының хәрби бүлегенә һәм хәрби революцион штабка җитәкче итеп билгеләнде.

Владивостоктагы восстание Лазо планы буенча хәзерләнде.

1920 нче елның 31 нче январенда Владивостокта ак генераллар власте бәреп төшерелде. Шул ук көннәрдә Благовещенскида, Хабаровскида һәм Никольск-Уссурискида ак гвардеецлар власте бәреп төшерелде.

5 нче апрельгә каршы төндә Владивостокта һәм Ерак Көнчыгышның башка шәһәрләрендә япон империалистларының провокацион чыгышлары башланды.

Шул төндә японнар Сергей Лазоны һәм Хәрби советның ике членын—Алексей Луцкийны һәм Всеволод Сибирцевны Тикшерү комитеты бинасында кулга төшерәләр, Лазо монда яшрен документларын юкка чыгара һәм хәрби частьләргә шәһәрдән чигенү турында боерык бирә.

Ерак Көнчыгыш партизаннарының һәм хезмәт ияләренең сөекле җитәкчесе Сергей Лазоны һәм аның иптәшләре Луцкийны һәм Сибирцевны япон империалистлары җәзалыйлар.

Апрель урталарында Лазоны, Луцкийны һәм Сибирцевны япон гаскәрләре урнашкан районга—Первая речка станциясенә алып китәләр. Май аенда аларны почта теплушкасына утыртып, японнар Муравьево-Амурская станциясенә (хәзер Лазо станциясе) алып китәләр һәм, капчыкларга салып, ак бандитларга — бочкаревчыларга тапшыралар.

Японнарның указы буенча бочкаревчылар большевикларны — Лазоны, Луцкийны, Сибирцевны ерткычларча җәзалыйлар. Аларны капчыкка салган килеш депога алып китәләр. ЕЛ—629 нчы номерлы паровоздан команданы куып төшерәләр дә, паровоз будкасына сөйрәп кертәләр. Сергей Лазоны капчыктан чыгаралар һәм тере килеш паровоз пиченә этеп кертергә тырышалар. Лазо, физик яктан көчле булганлыктан, каршылык күрсәтә. Көрәш башланып китә. Башына сугудан ул аңын югалта. Ерткычлар аны паровоз пичендә яндыралар.

Башка иптәшләре белән икенче төрле эш итәләр: аларны капчыктан чыгармыйча атып үтерәләр, аннары пичкә ыргыталар.

Күреп торучыларның сөйләүләре һәм сакланган материаллар нигезендә билгеле булган бу фаҗигәнең күренеше әнә шундый.

Себернең, Ерак Көнчыгышның хезмәт ияләре, бөтен совет халкы Сергей Лазоны беләләр һәм исләрендә тоталар.

Ольга Лазо.

Чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейде

РЕЙД ЗУР ЯРДӘМ КҮРСӘТӘ

ЮТАЗЫ, 3 апрель. (**Телефон буенча**). Ютазы районы колхозларында язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләреннән оештырылган 22 рейд бригадасы эшли.

Бригадалар колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекнең торышын тикшерү вактында уңышлы яклар белән бергә, күп кенә кимчелекләрне ачалар һәм аларны үз вактында бетерүгә ярдәм итәләр.

Бәйрәкә авыл советына караган „Чик бүләк“ колхозында үткәрелгән рейд нәтиҗәсе язгы чәчүгә хәзерлекнең торышы яхшы икәнлеген күрсәтте. Бу колхозның чәчү мәйданы 148,5 гектар, чәчү орлыклары җитәрлек.

Авыл хуҗалыгы машиналарына яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясалган. Агротехника чаралары планын үтәү эше дә яхшы бара. Кош тизәге җыю планы 122, минерал ашламалар ташу планы 200 һәм көл җыю планы 100 процент итеп үтәлгән.

Рейд бригадасы колхозчылар арасында политик-масса эшләрен дә алып бара. Шуның нәтиҗәсендә, чәчү орлыклары җитешмәгән колхозларга социалистик ярдәм итү йөзеннән колхозчылар үзләреннән арткан орлыкларын бирделәр. Колхозчылардан Мостафин 10 центнер, Бадыйков 4 центнер һәм күп кенә колхозчылар 2—3 центнер ашлыкларын яңа уңыштан кайтарып алу шарты белән бурычка бирделәр.

Дим Тамак авыл советына караган „Марс“ колхозында рейд бригадасы күп кенә җитешсезлекләрне ачты. Бу колхозда чәчү вактында атларны ашату өчен улаклар җитәрлек түгел. Рейд бригадасы ярдәме аркасында улакларны төзәтү эше башланды. Аның өчен кирәкле материаллар булдырылды. Монда минерал ашламалар хәзерләү һәм аларны тиешле урында саклау эшенә дә әһәмият бирелмәгән. 21 центнер **супер-фосфат** такта җәелмәгән җиргә салынган. Рейд бригадасы бу ашламаларны яхшы амбарга салып куйдыруны булдырды.

Активлык арта. 3 нче бригадада бер көн эчендә 4 центнер көл җыелды.

Рейд бригадасы ачкан кимчелекләр турында колхоз һәм бригада стена газеталарында яктыртыла, кимчелекләрне бетерү өчен чаралар күрелә.

ВКП(б) Өлкә Комитетының колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейден үткәрү турындагы карары чыкканга шактый вакыт үтеп бара. Ләкин ВКП(б) райкомы, район совет башкарма комитеты работниклары бу карарны тулысынча тормышка ашыруга салкынлык күрсәтәләр. Ютазы совхозында һәм МТС та шушы көнгә кадәр рейд бригадалары оештырылмаган. МТС та язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча „Бөгелмәдән рейд бригадасы килә“ дип тынычланып яталар.

Рейд бригадасы членнары:

К. Хөсни, Вахитов, Кәтиев.

Хәзерлек яхшы дип табылды

АКТАНЫШ, 3 апрель. (**Телефон буенча**). Эшче - авыл хәбәрчеләренең рейд бригадалары колхозларның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерү буенча практик эш алып баралар.

„Кызыл Көч“ колхозының язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерү буенча 5 әр кешедән ике бригада оештырылган иде. Бригадалар бу колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген яхшы дип таптылар.

Колхозда орлык тулысынча хәзерләнгән һәм чәчүгә яраклы кондициягә китерелгән. Колхоз үзеннән арткан 934 центнер орлык белән башка колхозларга ярдәм иткән. Кышкы агротехника чараларын үткәрү планы арттырып үтәлгән һ. б.

Хәзер колхозда бәрәңге яровойлаштыру, орлык агулау һәм басуда кар сулары тоту эшләре бара. Тирмик ысул белән 100 центнер орлык агуланган, 58 гектар мәйданда кар сулары тотып калу чаралары үткәрелгән һәм 150 центнер бәрәңге яровойлаштыруга салынган инде.

Рейд бригадалары язгы чәчү өчен кирәкле берничә машинаның ремонтын канәгатьләнмәслек дип тапканнар иде. Бу кимчелекләрне шунда ук бетерү чаралары күрелде. *Ж. Хисмәтуллина.*

КЫРЫК ИКЕ БРИГАДА

БАЛТАЧ, 2 апрель. (**Телефон буенча**). Балтач районында язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча 42 урында эшче-авыл хәбәрчеләренең рейд бригадалары оештырылды. Рейд бригадаларының җитәкчеләре ВКП(б) райкомы бюросында расланды. 2 нче апрельдә рейд җитәкчеләренең киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәгә 32 кеше катнашты.

Рейдкә райком секретарьлары Ильясов һәм Хисаметтинов иптәшләр җитәкчелек итәләр. Рейд бригадаларының членнары эшкә керештеләр. — *Х. Галләмев.*



Орденлы Актаныш МТС ы тракторчысы Хәят Вазеева 1940 нчы елны трактор белән 800 гектар эшләргә йөкләмә алды. Рәсемдә: иптәш Вазеева тракторны сынау вактында.
А. Михайлов фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы).

„КЫЗЫЛ УДАРНИК“ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕР ТҮГЕЛ

„Сугышчан хезмәтләре өчен“ медале белән бүләкләнгән иптәш Батыршин җитәкчелегендәге эшче-авыл хәбәрчеләре бригадасы Октябрь районының „Кызыл ударник“ колхозында язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерде. Бригада күп кенә кимчелекләрне ачты. Колхоздагы 170 центнер чәчүлек солы орлыгының бары 70 центнеры гына чистартылган. 4 культиватор җитешми. Производство планы колхозчылар җыелышында тикшерелмәгән.

Эшче-авыл хәбәрчеләре рейде эшенә алдынгы колхозчылар актив ярдәм күрсәтәләр.

(ТатТАСС).

ПУЧИ, 4 апрель. (**Телефон буенча**). Эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде бригадасы Калинин МТС ының язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерде. Тикшерү нәтиҗәсендә күп кенә кимчелекләр табылды. Эшчеләр арасында масса-аңлату эшләре гаять начар тора. МТС ның политик эшләр буенча директор урынбасары иптәш Шакиров эшчеләргә партия һәм хөкүмәтнең карарларын аңлатуны начар оештырган, стена газеталары вактында чыгарылмый, ремонтчыларга тиешле эш шартлары тудырылмаган, җылы аш хәзерләнми. Хәтта эшчеләргә кайнаган су да юк.

12 СТЗ, 2 ЧТЗ һәм бер дезиль тракторларына частьләр җитешми. Бер дезиль тракторы ремонттан да чыкмаган. 12 трактор сабаны эшкә яраксыз, 10 торак вагон һәм культура вагоннары ремонттан чыгарылмаган.

Рейд бригадасы тарафыннан ачылган җитешсезлекләрне тиз арада бетерергә такдим ителде.

Ханипов.

Укытучылар актив катнашалар

Биектау районының барлык колхозларында колхозларның язгы чәчүгә хәзерлеген массовый рәвештә тикшерү бара.

Авыл хәбәрчеләре Шебалов, Бузов һәм Абрамов иптәшләр составындагы бригада Сталин исемендәге колхозның чәчүгә хәзерлеген тикшергәннән соң, тикшерүнең нәтиҗәләре турындагы мәсьәләне колхозчыларның гомуми җыелышына куйды. Колхоз орлыклар белән тәэмин ителгән. Барлык авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясалган.

„На страже“ колхозында авыл хәбәрчеләре бригадасы зур гына җитешсезлекләрне ачты. Монда чәчүлек орлыклар җитешми. Атларны тәрбияләү эше начар. Колхоз транспорт средстволары белән тәэмин ителмәгән. Колхоз председателе Матвеев эшлексезлек күрсәтә.

Колхозларның чәчүгә хәзерлекләрен тикшерүдә укытучылар актив катнашалар. Чепчуги урта мәктәбе директоры иптәш Якушев һәм Биектау урта мәктәбе директоры иптәш Козлов колхозның чәчүгә хәзерлеген тикшерүне оештырдылар. Алар җитешсезлекләрне бетерүдә авыл советларына актив ярдәм итәләр.

(ТатТАСС).

Казан Авыл Хуҗалыгы институтының үсемлекләр буенча кафедра мөдире иптәш К. И. Попов. Ул 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуга кандидат.
И. С. Папков фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы)

КАР СУЛАРЫ ТОТУ

Беренче Май районының алдынгы колхозлары 3 мең гектар мәйданда кар сулары тотуга керештеләр. „Новый путь“, „Тырыш“ һәм Пушкин исемендәге колхозлар 60 гектар мәйданда кар суы тоттылар. Кар суы тотуны оештыруда практик ярдәм күрсәтү өчен ВКП(б) райкомы партия һәм комсомол активын колхозларга җибәрде. Агрономнарның, агротехникларның һәм кырчыларның шушы көннәрдә генә булган киңәшмәсе туңга сөрелгән барлык участкыларда да кар суы тотуны оештырырга йөкләмә алды.

Баулы районында соңгы ике көн эчендә 550 гектар мәйданда кар суы тотылды. „Победа“ колхозы алдынгы булып бара. Монда 170 гектар мәйданда кар суы тоту буенча эш үткәрелде.

Ширәмәт районының күп кенә колхозларында кар суы тоту эшләре бара. „Ленинский путь“ колхозында ике көн эчендә 70 гектар җирдә кар суы тотылды. Киров исемендәге, Нәриман исемендәге һәм „Борец революции“ колхозларында да кар суы тоту эше яхшы бара.

Ләкин бөтен килеш алганда, районда бу эшнең үткәрелеше канәгатьләнерлек түгел. Монда план буенча 2 мең гектар җирдә кар суы тотылырга тиеш иде, ләкин әле бары 500 гектар чамасы мәйданда гына кар суы тотылган. „Красный партизан“, „Болгар“ колхозларында һ. б. кар суы тоту эшенә һаман керешмәгәннәр әле. Комсомол райкомы кайбер колхозларга үзенең вәкилләрен җибәргән дә, шуның белән тынычланып калган.

(ТатТАСС).

Агроном киңәшләре

ГӨМБӘ БЕЛӘН КӨРӘШ— УҢЫШ ӨЧЕН КӨРӘШ

Гөмбә белән көрәш мәсьәләсе агротехника чараларының әһәмиятле бер тармагы булып санала. Чөнки гөмбә уҗым һәм сабан ашлыкларына бик зур зиян китерә. Ул бик куркынычлы, тиз тарала торган, уңышта зур югалтулар китереп чыгара торган авыру. Ашлыкларның гөмбә белән зарарлануы күбесенчә чәчү орлыгы аша булганлыктан, гөмбә белән көрәш, башлыча, орлыкларны гөмбәдән арындыру—орлыкларны агулау юлы белән барырга тиеш.

Орлыкларны агулау яңа нәрсә түгел, әлбәттә. Ләкин колхозларда агулау техникасына әһәмият биреп җиткермәгәнлектән, ашлыклар әле һаман да гөмбә белән зарарланган булалар. Бу, уңышны киметә. Мәсәлән, Теләче районы үткән ел шуның аркасында уңышның 2,56 процентын, Кызыл Йолдыз районы колхозлары уртача 2,44 процентын югалттылар.

Ә орлыкларны агулау техникасына игтибар иткән урыннарда уңыш яхшы булды. Актаныш районында сабан бодаеның гөмбә белән зарарлануы елдан-ел кими. Әгәр дә Актаныш районы колхозлары сабан бодаенда булган каты гөмбә аркасында 1937 нче елда уңыштан 7,9 процентын югалткан булсалар, 1939 нчы елда бу процент 0,08 гә төште, Минзәлә районында 5,68 дән 0,03 кә, Октябрь районы колхозларында 0,26 дан 0,01 гә төште.

Ашлыкларда гөмбә булмасын өчен чәчү орлыкларының барсын да: бодай, солы, арпа, җитен һәм клеверны йөз проценты белән агуларга кирәк.

Юеш (каты) гөмбәле бодай, гөмбәле солы, каты гөмбәле арпа, тузан гөмбәле тары химик юл белән агулана.

Тузан гөмбә яралгычлары зарарланган орлыкның эчендә булганлыктан, андый орлыкны гади химик средстволар белән (коры һәм юеш) агулау тиешле нәтиҗәне бирми. Шунлыктан мондый чәчү орлыклары кайнар суда чылатыла. Бу—термик агулау ысулы, дип атала.

Термик ысул белән агулау тузан гөмбәне үтерү белән бергә, бодайдагы каты гөмбәне дә бетерә. Шуңа күрә дә термик агулаудан соң бодайны һәм арпаны химик юл белән агулауның кирәге юк.

Селекция станцияләре, районнарның орлыкчылык хуҗалыгы, колхозларның һәм совхозларның орлыкчылык участкыларының чәчүлек орлыклары һич шиксез термик ысул белән агуланырга тиешләр.

Термик агулау түбәндәге стадияләр аша үтә:

1. Башта, орлык эчендәге тузан гөмбәнең гөмбәчеген (грибница) үстерә башлату өчен орлыкны Цельсия буенча 28—32 градуслы кайнар суда 4 сәгат буена чылатырга кирәк.

2. Үсәргә кузгалган гөмбәчекләрне үтерү өчен исә бодай һәм арпа Цельсия буенча 52 градуслы кайнар суда 8 минут, ә 53 градуслы булганда 7 минут чылатыла.

3. Аннан соң, кайнар суның орлыкка йогынтысы булмасын өчен орлык салкын суга салына.

4. Орлыклар салкын судан чыгаргач киптереләләр.

Орлыкны кайнар суда чылаткан вакытта орлык эчендәге температура Цельсия буенча 53 градустан артык һәм 52 градустан ким булмаска тиеш, юкса суның градусы артып киткәндә орлыкның тишелеш көче кими, ә градус түбән булганда тиешле нәтиҗәне бирми.

Суның градусын санау вакты температура орлык уртасында 52 яки 53 кә җиткән вакыттан башлана. Үлчәү Цельсия термометры белән алып барыла. Термометр дөрес күрсәтә торган булырга тиеш.

Орлыкны термик кайнарлату өчен файдаланыла торган барлык инструментларны җентекләп дезенфикцияләргә кирәк. Дезенфикция ясау өчен кырык процентлы формалинның бер өлешенә 100 өлеш су кушып, сыекча ясалына. Кайнарлатылган орлык белән чәчелгән кырлар кайнарлатылмаган орлык белән чәчелгән мәйданнан 300 метр читтә булырга тиеш.

Бодайны һәм арпаны термик агулау Ходоковский установкаларында һәм гади коралларда: чиләкләр, чаннар, мичкәләрдә алып барыла. Су җылыту өчен казаннар, су кайнаткычлар, терлек азыгы парлагычлары файдаланылалар.

Хуҗалык чәчүлекләренә чәчеләчәк бодай „Давидов“ препараты белән коры ысулда агуланыла. Агулау 1 тонна орлыкка 1 килограмм „Давыдов“ агуы яки 1 тонна орлыкка 2 килограмм АБ препараты яки кырык процентлы формалинның бер өлешенә 300 өлеш су кушып ясалган сыекчада үткәрелә.

Бодай орлыгында каты гөмбә күп булганда, бодайны эчке ягы капчык белән тегелгән кәрзиннәргә салып, кадкада формалин сыекчасына манчып алу юлы белән агулау шарт. Шул вакытта формалин сыекчасы өстенә калкыган чүпләрне һәм гөмбәләрне алып ташларга һәм юкка чыгарырга кирәк.

Арпа, солы һәм тары орлыкларын юеш ысул белән кырык процентлы формалинның бер өлешенә 300 өлеш су кушып ясалган сыекчада агуланыла. Солы һәм арпа орлыкларын формалин сыекчасы белән ярым коры ысул белән дә агуларга мөмкин. Моның өчен кырык процентлы формалинның бер өлешенә 80 өлеш су кушыла.

Формалин белән юеш һәм ярым коры ысул белән агулауны бу орлыкларны чәчү алдыннан 2—3 көннән дә элек эшләргә ярамый.

Хәзер, техник культуралары орлыкларын агулау турында бер-ике сүз. Чәчү өчен билгеләнгән җитен һәм клевер орлыклары чүпләрдән һәм чүп үләне орлыкларыннан тазартылырга һәм орлыкларның дымлыклыгы 13 проценттан югары булмаска тиеш. Җитен орлыгын, аны чәчүгә ике-өч көн калгач агуларга кирәк, ә клевер орлыгын исә чәчкәнче ай ярым—ике ай элек агуларга мөмкин. Җитен орлыгын агулау өчен „Давыдов“ препараты 1 тонна орлыкка кило ярым, ә клевер орлыгына—1 тоннага 2 килограмм алына.

Агулау эше моның өчен махсус эшләнгән: „Идеал“, „Урожай“, „АБ—2“ машиналарында үткәрелә. Әгәр дә бу машиналар булмый икән, ул чагында агулау өчен махсус хәзерләнгән мичкәләрдән файдаланырга мөмкин.

Татарстанда орлык агулау материаллары җитәрлек. Колхозларның бурычлары—агулау препаратларын вактында кайтартудан һәм агулау техникасына бик нык әһәмият бирүдән гыйбарәт. Чәчү орлыкларын агулауны яхшы оештыру белән гөмбәгә каршы нык көрәшеп, иген уңышын күтәрергә зур ярдәм итик.

Агроном *Х. Н. Чанышева.*

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫН АЛДЫНГЫЛАР САФЫНА ЧЫГАРЫРГА

Казан тимер юлының кышкы шартларда эшләү йомгаклары һәм язгы, шулай ук җәйге йөк ташуларга хәзерлек мәсьәләсе шушы көннәрдә ВКП(б) Өлкә Комитеты тарафыннан үткәрелгән махсус киңәшмәдә тикшерелде.

Казан тимер юлы берничә еллардан бирле инде хурлыклы рәвештә артта калып килә. Монда йөк төяү һәм бушату планы да, паровозлар паркының техник тизлелек һәм вагоннар әйләнеше нормасы да айдан-айга үтәлми. Аварияләр һәм крушениеләр кебек хурлыклы күренешләр хәзергәчә бетерелмәгән.

Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Ни өчен Казан тимер юлы һаман да бер урында таптана? Чөнки монда, гаять катлаулы һәм җаваплы эш тармагында большевистик тәртип урнаштырылмаган. Артта калуның төп сәбәбе—эш участкыларына оператив җитәкчелек итмәүдә, кадрларны дөрес урнаштырмауда һәм аларны большевизм рухында, үзләренә тапшырылган эш өчен нык җавапчылык сизү рухында тәрбияләүнең һич тә канәгатьләнерлек булмавында, масса сигналларына сизгер колак салмауда һәм тимер юл транспортының Сталинчыл наркомы иптәш Кагановичның сугышчан күрсәтмәләрен тайпылышсыз үтәү өчен көрәшкә тимер юлчылар армиясен кирәгенчә тупламауда. Казан тимер юлы начальнигы Пичугин һәм политбүлек начальнигы Мандур иптәшләрне Татарстан большевикларының өлкә конференциясендә һәм тимер юл партактивы җыелышында коммунистлар әнә шуның өчен тәнкыйтьләделәр.

Чыннан да, Әгерҗе һәм Юдино бүлекләренең соңгы вакытларда аеруча начар эшләүләрен нәрсә белән аңлатырга? Юдино бүлегендә, төзек бумаган паровозларның саны планга караганда 11 процент, Әгерҗедә 24 процент артык булуы турында, юллар хуҗалыгының таркау хәлгә китерелүе, Техник Эксплоатация Кагыйдәләрен өйрәнү эшенең формаль рәвештә генә оештырылуы һәм башка шундый җидди кимчелекләр Казан тимер юлы идарәсе җитәкчеләренә күптән билгеле булса да, бу аянычлы хәлгә нәтиҗә ясаучы кеше юк.

Вагоннар паркында да шундый ук җитешсезлекләр хөкем сөрә. Әгерҗе һәм Юдино бүлекләрендә ремонт эшләренең сыйфаты чиктән тыш начар булу аркасында, яңадан ремонтка кергән вагоннарның саны һәр ай саен 450—500 дән кимеми. Ә бит бу хәл вагоннар паркы әйләнешенә зур тоткарлык ясый. Моңа тагын клиентлар гаебе белән булган простойларны өстәсәк, вагоннар паркының эшсез торуы коточкыч күләм ала. Ленин исемендәге завод һәм Вахитов исемендәге жиркомбинат кебек предприятиеләр үзләренә бирелгән вагоннарны вактында бушатмаулары һәм төямәүләре өчен соңгы 3—4 ай эчендә генә дә Юдино бүлегенә 300 мең сумнан артык штраф түләргә мәҗбүр булганнар. Ләкин дисциплинасызлык күрсәтүче, дәүләт акчаларын әрәм-шәрәм итүчеләргә карата тиешле чаралар күрелми. Суд һәм прокуратура работниклары бу хәлгә килешүчәнлек күрсәтәләр.

Атаклы машинист орденлы Крылов, аталы-уллы Захаровлар, Колыганов, Шкатов, Волгушев, Парыгин, составитель Гарев, Блинов, Асахов, Мусин кебек үз эшләре техникасын отличнога үзләштергән гүзәл кадрларны Казан тимер юлы берничә йөзләп саный. Ләкин алдынгыларның бай тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү эше белән бүлек җитәкчеләре дә, шулай ук Казан тимер юлы идарәсе җитәкчеләре дә шөгыльләнмиләр диярлек. Стахановчылык - кривоносчылык хәрәкәтенә җитәкчелекнең чиктән тыш начар булуы нәтиҗәсендә, соңгы вакытларда стахановчылар һәм ударниклар саны кискен рәвештә кимегән. Мәсәлән, 1939 нчы елның ноябрендә Әгерҗе һәм Юдино бүлекләрендә стахановчылар 1.400 дән артык исәпләнгән булса, хәзер аларның саны 900 кешедән артмый.

Партия һәм комсомол оешмалары производство мәсьәләләре белән йомшак шөгыльләнәләр. Әгерҗе депосы партоешмасында (партбюро секретаре иптәш Ганьков) производство мәсьәләләре 3—4 ай буена бер тапкыр да тикшерелмәве моның ачык күрсәткече. Коммунистларның производствода авангардлык рольләре түбән. Әгерҗе депосында 90 коммунистның 23 е генә, Юдинода 120 коммунистның 68 е генә стахановчы булып исәпләнә. Бу начар күренеш, әлбәттә. Без һәрбер коммунистның үз эшендә чын-чынлап авангард булуына ирешергә тиешбез.

Партиябез һәм хөкүмәтебез бездән кадрларга игтибарлы булуны, аларны һәр яклап тәрбияләүне, яшь работникларга көндәлек ярдәм күрсәтүне таләп итәләр. Ә менә Казан тимер юлында бу эшнең торышы гафу ителмәслек начар. Эш көчләренең агылышы коточкыч зур күләм алган. Узган елны гына да 18 меңнән артык кеше эштән киткән. Кадрларны игтибар белән тәрбияләү эше коры администраторлык белән алыштырылган. Мәсәлән, Юдино бүлегендә приказ буенча шелтә алмаган бер генә җитәкче работник та юк диярлек.

Үтәлешне тикшерү—Казан тимер юлында онтылган тармакларның берсе. Моны раслау өчен бер генә факт китерү дә җитә. Аварияләргә һәм крушениеләргә каршы көрәш һәм техника укуларын оештыру турында Казан тимер юлы начальнигы иптәш Пичугинның 3—4 приказы бар. Шулай да, бу приказларның урыннарда ничек үтәлүе бер кем тарафыннан да һәм бер кайчан да тикшерелгәне булмаган. Бу хәл исә кайбер работникларның үз эшләрендә җавапсызлык күрсәтүләренә юл куюга, Техник Эксплоатация Кагыйдәләрен бозуга алып бара.

Җәйге сезонга, юлларны ремонтлау сезонына хәзерлек турында бер-ике сүз. Бу өлкәдә быел гаять зур эшләр башкарылачак. 569 километр юлга капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрелергә тиеш. Ләкин бу җаваплы эшне башкаруга хәзерлек үз агымына куелган. Рельсләр, шпаллар һәм балласт мәсьәләсе әле дә булса хәл ителмәгән. Төзелеш сезоны өчен таләп ителгән эш көчләренең әле яртысы да тупланмаган. Төзелеш сезонына хәзерлек мәсьәләсе нәтиҗәсез сөйләнүләргә генә кайтып кала. Бу эш белән турыдан-туры шөгыльләнергә тиеш булган иптәш Пудонин (Казан тимер юлы начальнигының урынбасары) гафу ителмәслек сүлпәнлек күрсәтә.

Казан тимер юлының эше якын арада сәламәтләндерелергә, аның үрнәк эшләве өчен барлык чаралар күрелергә тиеш. 7 нче апрельдән 10 нчы апрельгә кадәр үтәчәк тимер юл активы җыелышларын әнә шул лозунг астында үткәрергә кирәк.

М. Гайнеттинов.

ВКП(б) Өлкә Комитетының транспорт бүлеге мөдире.

РАЙОНАРА ЯРДӘМ

Башта, Арча районының байтак колхозларында чәчү орлыгы җитми иде. Үзләрендә чәчү орлыгы арткан колхозлар бу колхозларга орлыкны көтәргә биреп тору юлы белән ярдәм иттеләр. Шулай итеп районның барлык колхозлары да чәчү орлыгы белән тулысынча тәэмин ителде.

Соңгы вакытта күп кенә колхозлар үзләреннән арткан чәчү орлыгы белән башка район колхозларына ярдәм итү эшен җәеп җибәрделәр. „Татарстан № 2“ колхозы 550 центнер, „Орняш“ колхозы 273 центнер, „Якты Юл № 3“ колхозы 270 центнер, „Спартак № 1“ колхозы 250 центнер чәчү орлыгын башка район колхозларына бирделәр. Шулай итеп, икенче район колхозларына 3.728 центнер орлык бирелде инде. Колхозларда бу эш дәвам итә.

К. Рамазанов.

Чит илләрдә

Англиянең хөкүмәт составында үзгәрешләр

ЛОНДОН, 3 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия кабинеты составында түбәндәгечә үзгәрешләр булган: оборона координациясе буенча министр Чэтфилд отставкага чыккан; печать саклаучы лорд Сэмюэль Хор авиация министре итеп билгеләнгән; Элекке авиация министре Кингсли Вуд печать саклаучы лорд итеп билгеләнгән; лорд Вултон азык белән тәэмин итү министре итеп билгеләнә; тышкы сәүдә департаментының элекке житәкчесе Хадсон сәүдә пароходчылыгы министре итеп билгеләнә; элекке почта министре Трайон Ланкастер герцоглыгының канцлеры итеп билгеләнгән; Ланкастер герцоглыгының элекке канцлеры һәм азык белән тәэмин итү министре Моррисон бу хезмәтләреннән азат ителә һәм почта министре итеп билгеләнә; элекке җәмагат эшләре министре Рәмсботэм мәгариф министре итеп билгеләнә; элекке мәгариф министре Де ла Варр җәмагат эшләре министре постын ала; диңгез министрлегенең элекке парламент һәм финанс секретаре Шекспир тышкы сәүдә департаментына Хадсон урнына җитәкче итеп билгеләнә; сугыш министрлегенең элекке финанс секретаре Уорендер диңгез министрлегенең парламент һәм финанс секретаре итеп билгеләнә; информация министрлегенең элекке парламент секретаре Эдвард Григг сугыш министрлегенең финанс секретаре итеп билгеләнә.

Диңгез министре Черчилль үз постында кала һәм шуның өстенә диңгез министрлегеннән, сугыш министрлегеннән һәм авиация министрлегеннән гыйбарәт булган комитетка җитәкчелек итәчәк. Бу комитет әледән-әле утырышлар ясап торачак һәм анда киңәшчеләр сыйфатында авиация, диңгез һәм сугыш генеральный штабларының начальниклары катнашачак. Агентлыкның хәбәр итүенә караганда, бу комитет хәрби кабинет исеменнән стратегик обстановкадагы барлык иң әһәмиятле факторларны, сугыш операцияләренең барышын һәр вакыт тикшереп торачак һәм сугышка гомуми җитәкчелек турында хәрби кабинетка вакыт-вакыт үзенең рекомендацияләрен биреп торачак.

Печать саклаучы лорд Кингсли Вуд бер үк вакытта эчке политика комитеты председателе дә булачак. Бу комитет илнең эчке хәленең барлык мәсьәләләрен, шулай ук яңа законнар турындагы тәкъдимнәрне тикшерәчәк. Шул ук вакытта Кингсли Вуд азык политикасы комитетының председателе булачак. Бу комитетның хезмәте илдә азык политикасын билгеләүдән һәм авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә җитәкчелек итүдән гыйбарәт булачак. Финанс министре Джон Саймон экономик политика комитеты председателе булып калачак. Авиация министре ярдәмчесе итеп лорд Ривердейл билгеләнә. Ул авиация министрлеге янындагы тәэминат комитетының председатель урынбасары булачак.

Рәсми белдерүдә хәбәр ителүенчә, кайбер министрләр хөкүмәтнең яңа составында әһәмияте азрак булган постларны алганнар. Бу нәрсә сугыш шартларында һәрбер министрдән яхшырак файдалануны күздә тотып эшләнгән. Отставкага чыккан оборона координациясе министре Чэдфилд урнына яңа кеше билгеләнмәячәк. Хәрби тәэминат министрлеге Черчилль җитәкчелегендәге комитетка кушылачак.

Оборона координациясе буенча элекке министр Чэтфилд үзенең отставкасы турында Чемберленга язган хатында болай дигән: „Тыныч вакытта оборона координациясе министре посты бик кирәк булса да, сугыш шартларында, үзенең составына барлык хәрби министрләр керә торган хәрби кабинет оештырылганда оборона координациясе министренең җаваплылыгы әлбәттә бик нык кими, чөнки сугыш хәрәкәтләренә координация бирүгә җитәкчелек итү һәм кирәкле карарларны кабул итү үзеннән-үзе баш министр кулына күчә“. Чэдфилдның хатына язган җавабында Чемберлен аңа отставканы кабул иткәнлеген белдергән.

Көнбатыш Европа сугышы

ПАРИЖ, 2 апрель. (ТАСС). Гавас агентлыгы түбәндәгеләрне тапшыра: „31 нче мартта кич белән сугыш вакытында Франциянең ике истребителе бәреп төшерелде.

Кичә Франция самолетлары фронт урыннарын фото рәсемгә төшерделәр. Германия самолетлары Шотландиянең төньяк ярлары өстендә күренделәр. Германиянең бер самолеты бәреп төшерелде.

Фронтта Саарбрюкеннан көньяктарак булган районда артиллериядән көчле атышулар булды“.

БЕРЛИН, 3 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге сводканы иглан итте:

„Көнбатыш фронтта разведка отрядларының җанлы хәрәкәте. 2 нче апрельдә Германия авиациясе Төньяк диңгез өстендә—Англиянең көнчыгыш ярлары өстендә күзәтү очышларын дәвам иттерде. Англиянең өч истребителе белән булган сугыш нәтиҗәсендә Германиянең бер самолеты су өстенә төшәргә мәҗбүр булды. Көнбатыш чиктә фронтның күп кенә участкыларында һава сугышлары булды. бу сугышлар вакытында дошманның өч истребителе бәреп төшерелде. Германиянең ике самолеты үз базаларына кайтмады“.

ПАРИЖ, 3 апрель. (ТАСС). Кичә Вогезыдан көнбатышта артиллериядән атулар булу турында рәсми рәвештә хәбәр ителә. Һавада Франция истребительләре белән Германия самолетлары арасында берничә бәрелеш булган. Бу сугышлар вакытында Германиянең ике моторлы ике самолеты бәреп төшерелгән. Франциянең бер самолеты үз базасына кайтмаган.

Төнлә белән фронтта бер нинди яңалык булмаган.

Швеция хөкүмәтенең декларациясе турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 3 апрель. (ТАСС). Англиянең чит ил эшләре министренең 12 нче мартта, гүяки Финляндиянең бик нык таләп итүе буенча, союзникларның гаскәрләрен үткәрергә рөхсәт сорап Швециягә мөрәҗәгат иткәнлеге турында 1 нче апрельдә Швециянең баш министре Гансон тарафыннан ясалган белдерү Лондонда ачыктан-ачык буталыш тудырды, чөнки финнәр үзләренең Англиягә мөрәҗәгат итмәгәнлекләрен ачыктан-ачык белдерәләр. Кичәге газеталарның Гансон речение бу өлеше турында бөтенләй язмауларлы, яки аны күренмәслек урынга гына урнаштырулары мондый буталыш туганлыкны ачык күрсәтә.

Сливнода Болгария—Совет җәмгыятенең бүлеге төзелү

СОФИЯ, 3 апрель. (ТАСС). Сливно шәһәрендә Болгария—Совет җәмгыятенең бүлеге төзелде. Бүлекне ачуга багышланган тантаналы җыелышта адвокатлардан, архитекторлардан, врачлардан, эшчеләрдән, кустарьлардан һәм башкалардан 200 дән артык кеше катнашты. Җыелышта правление һәм ревизия комиссиясе сайланды, шулай ук җәмгыятнең уставы расланды. Бу җәмгыят Болгария белән Советлар Союзы арасында культура һәм сәүдә мөнасәбәтләрен үстерүгә булышлык итүне үзенең бурычы итеп куя.

Япониянең Макаоны блокадалавы

ЛОНДОН, 3 апрель. (ТАСС). „Ньюс кроникл“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Португалиянең Гонконгдан көнбатыштагы Макао колониясе асылда хәзер японнар тарафыннан блокадаланган. Шәһәрдә азык мәсьәләсе чиктән тыш авыр. Португалия властьлары японнарның таләпләренә риза булып, үзләренең гаскәрләрен Лаппа һәм Ваньчжай атауларыннан алганнар, японнар киләчәктә бер нинди яңа дәгъвалар куймаячакларын белдергәннәр.

НЬЮ-ЙОРК, 3 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгы Макаога блокада ясалу турында хәбәр итеп, Гонконгка азык әйберләре кертүдә шулай ук кыенлыклар артканлыкны күрсәтә.

Португалиянең Япониягә протесты

НЬЮ-ЙОРК, 3 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Португалия властьлары японнарның Макаога кул сузуларына каршы протест белдергәннәр.

Кытайда сугыш хәрәкәтләре

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Сяодун районында кытай гаскәрләре японнарның коммуникацияләрен өзә алдылар.

Японнарның мең кешедән артык булган отряды Кантоннан көнбатыштагы Самшуйдан көньяк-көнбатышта Сидзян елгасын үтеп чыкты һәм кытайларның позициясенә атака ясады. Сугыш бер тәүлек дәвам итте, шуннан соң японнар кысрыклап чыгарылдылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньси провинциясенең көнбатыш өлешендә японнарның 2.000 кешелек колоннасы Цзикоу-Чунту районында Хуанхэ елгасы аркылы кичү урнына таба хәрәкәт итә башлады. Бу кичү бик әһәмиятле, чөнки ул Шаньси провинциясенең төньяк өлешенә бара торган туры юл белән кушыла. 24 һәм 25 нче мартта монда Ланьсян янында сугышлар булган, аннан японнар кытай гаскәрләренең басымы астында чигенергә мәҗбүр булганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Кытай гаскәрләре Чжэцзян провинциясендәге Фуяннан һәм Ханчжоудан төньяк юнәлештә алга баралар. Фуян—Ханчжоу шоссе юлында алар күперне шартлатканнар һәм урны-урны белән шоссены җимергәннәр.

3 апрель.



Ленин ордены һәм Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән Н-че чик буе отрядында. Рәсемдә: Капитан А. Я. Климов атлы спорт ярышына хәзерләнә.
Н. Кубеев фотосы (ТАСС фото-клишесе).

Мәктәптә үзешчәнлек сәнгате олимпиадасы

Минзәлә районы, Күзкәй урта мәктәбендә укучыларның үзешчәнлек сәнгате олимпиадасы үткәрелде. Олимпиадада җыр, бию, декламация һәм гармонда уйнау белән 50 гә якын укучы катнашты.

Олимпиадада җыр һәм декламация буенча беренче урынны 9 нчы класс укучысы Рәхмәтулла Зиннәтуллин алды. Ул мәктәп дирекциясе тарафыннан 100 сум акча белән бүләкләнде. Бию буенча икенче урыннарны Миңнегулов, Шакирова һәм гармонда уйнау буенча Гайнеттиновлар алдылар. Аларның һәрберсе 50 шәр сум акча белән бүләкләнде. Олимпиадада оста башкаручыларга 450 сумлык төрле бүләкләр бирелде. Беренче һәм икенче урыннарны алган укучылардан 6 кеше район олимпиадасына катнашу өчен билгеләнде.

Чураев.

Кино-журналның чираттагы номеры

Союзкинохрониканың өч республика студиясе, кино-журналның чираттагы номерын чыгаруга хәзерләнә. Журналның бу номерында Казанда ачылган А. М. Горький музей-йорты, Ижевский медицина институтының профессоры Н. Г. Статницкийның 40 еллык юбилее, Иошкар-Оладагы Ната Бабушкина исемендәге аэроклубта җәйге очу сезонына хәзерлек, яш үсмерләрнең Казанда үткәрелгән Бөтенсоюз гимнастика ярышларында җиңеп чыккан Казан командасы алынды.

Шулай ук бу журналга татар совет әдәбиятының күренекле язучысы Шәриф Камалның 30 еллык юбилей тантанасы да кертелде. Журнал тавышлы итеп эшләнә. Ул якын көннәрдә шәһәр кино-театрлары экраннарына чыгарыла.

Зоопаркта

Ботаника бакчасы территориясендәге зоопарк үзенең язгы-җәйге сезонына хәзерләнә. Аның барлык җанварлары кыш көне звериинецта торалар. Май аенда алар паркка күчереләләр һәм зоопарк 15 нче майда ачылачак. Шушы көннәрдә паркта ремонт башлана. 1940 нчы ел башында Казан зоопаркына күп кенә җанварлар һәм кошлар алынды. Алар арасында көмешсыман барс, гиена һәм енотлар, урман тавыклары, пеликаннар һәм башкалар бар. Сезон ачылуга зоопаркка яңа төр җанварлар партиясе алыну көтелә.

Татарстанның районнарына һәм күрше республикаларга җибәрү өчен күчмә бер филиал төзү дә күздә тотыла.

Татарстанда

Татарстанның суд-прокуратура работникларын ял йортларына җибәрү өчен быел 88 путевка, курортларга җибәрү өчен 17 путевка бирелә. Узган ел курортларга 13 кеше, ял йортларына 66 кеше җибәрелгән иде.

* * *

Татарстан Сәнгат Идарәсе янында театр әйберләре җитештерү конторасы төзелде. Ул Казандагы һәм районнардагы театрлар өчен үз предприятиеләрендә кием-салым һәм башка әйберләр эшләп чыгарачак.

* * *

Быел Казан Авыл Хуҗалыгы институты фермасында 5 гектар мәйданда яңа питомник ясала. Анда яхшы сорт крыжовник, виктория җиләге һәм кура җиләге үстереләчәк.

* * *

Алабугадагы электр станциясен реконструкцияләү эшләре бара. Быел аны тәгәлләү өчен 180 мең сум кредит җибәрелде.

* * *

Ширәмәт районы үзәгендә 400 урынлы яңа мәктәпне төзү тәгәлләнде. Мәктәп шушы көннәрдә эксплоатациягә бирелде.

* * *

„Спартак“ комбинаты янындагы ел ярымлык ФЗУ мәктәбен 57 кеше тәмамлады. Алар комбинат өчен квалификацияле эшчеләр булып хәзерләнделәр. Шулар арасында 24 кеше комсомолецлар.

* * *

Әлмәт МТС ы янында оештырылган тракторчылар хәзерләү курсында укулар тәмам булды. 4 айлык курстан 42 кеше хәзерләнеп чыкты. Аларның 8 е хатын-кызлар. Яш тракторчыларның барсы да трактор бригадаларына беркетелделәр.

* * *

1939 нчы елда Арча районы саклык кассаларында (районда барлыгы 8 саклык кассасы бар) 4.252 кеше үзләренең 81 мең сум акчаларын сакладылар. Үткән ел вкладларда сакланган акчалар хисабыннан 14.144 сум күләмендә процент түләнде.

Тракторчылар хәзерләү

Алабуга районының күп кенә колхозларында производстводан аерылмыйча тракторчылар хәзерләү курслары оештырылган иде. Курсларда Калинин исемендәге колхоздан 7 кеше, Сталин исемендәге колхоздан 9 кеше, „Смычка № 2“ колхозыннан 13 кеше укыды. Хәзер алар практик эшкә җибәрелделәр.

С. Сафиуллин.

Елгаларда

4 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Волга суы Вязовые янында 28 сантиметр, Югары Ослан янында 25 сантиметр, Кама Тамагы янында 30 сантиметр, Тәтеш янында 40 сантиметр артты. Ташу башланганнан бирле Югары Ослан янында арткан су 2 метр 11 сантиметрга житте.

Кама суы соңгы бер тәүлек эчендә Алабуга янында 40 сантиметр, Чистай янында 18 сантиметр, Лаеш янында 31 сантиметр артты.

Окада Кашира һәм Калуга янында боз ага. Рязань янында 56 сантиметр, Касим янында 44 сантиметр су артты.

Агыйдел суы бер тәүлек эчендә Уфа янында 55 сантиметр, Бирский янында 69 сантиметр артты. Ык суы Абсалəм янында 60 сантиметр, Чишмә суы Петропавловка янында 43 сантиметр, Мишә суы Рождествено янында 58 сантиметр, Казанка суы Арча һәм Казан янында 50 сантиметр күтәрелде.

Терлекчелекне үстерү өчен кредитлар

Татарстан колхозларында терлекчелекне үстерү өчен узган ел Авыл Хуҗалыгы банкысыннан 7 миллион 100 мең сум кредит бирелгән иде. 1940 нчы елга шул ук эшләр өчен 8 миллион 40 мең сум кредит билгеләнде. Бу акчаның 5 миллион 700 мең сумы колхозларның терлекчелек фермаларына терлекләр сатып алу өчен, 2 миллион 340 мең сумы фермаларда терлек абзарлары, силос башняләре һәм башка төрле биналар салу өчен тотылачак.

Көндәлек вакыйгалар

Бәхетсезлеккә очрау. Старый урамдагы 17 нче йортта торучы Петров исерек хәлендә 3 нче маршрут трамвай вагоныннан сикереп төшкән чагында тагылма вагон астына егылган. Вагон көпчәге аның ике аягын да өзеп киткән. Петров авыр хәлдә 5 нче больницага китерелсә дә, берничә минуттан соң үлгән.

Теләче районыннан килгән Шәһвәли Садыйков дигән 14 яшьлек малай Татарстан урамында трамвай баскычына утырып барган вакытта егылып төшеп, кабыргасын сындырган. Аны ашыгыч ярдәм автомобиле белән больницага җибәргәннәр.

Белдерү

8 нче апрельдә Менжинский исемендәге клубта Казан шәһәре комсомол активының җыелышы чакырыла. Көн тәртибе: ВЛКСМ Үзәк Комитеты X нчы пленумы карарларының үтәлешенең барышы турында. Җыелышка керү өчен билетлар ВЛКСМ ның шәһәр һәм район комитетларында бирелә.

ВЛКСМ ның Казан Шәһәр Комитеты.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Франциянең коммунист депутатларына суд процессы

(Брюссельдән хат)

Парижның хәрби трибуналында 13 көн буена Франциянең 35 коммунист депутатының эше тыңлана.

Үзенең империалистик реакцион теләкләренә ирешү өчен француз халкының чын вәкилен—коммунистлар партиясен тар-мар итәргә омтылган Франция хөкүмәте „демократик“ Франциянең хокук нормалары белән хисаплашмады. Франция властьлары 1875 нче елның 16 нчы июль конституциясен тупас төстә боздылар. Бу конституциянең 13 нче статьясендә „ике палата членнарының берсе дә үзләренең фикерләре яки тавыш бирүләре нигезендә гаепләнә яки судка бирелә алмыйлар“ диелгән.

Франция хөкүмәте халык вәкилләренә каршы процесс оештырып кына калмады, бәлки коммунистларны—парламент членнарын присяжныйларның гади суды гаепләмәс дип, аларны хәрби суд кулына тапшырды.

Ләкин хәрби суд та бу оятсыз процессны ачык итеп үткәрергә батырчылык итмәде. Бу эш ябык рәвештә тыңлана. Судның бары беренче утырышы гына ачык булды. Процесс башлануның беренче көненнән соң ук суд, процесста катнашучы эшчеләр массасының гаепләнүчеләргә карата булган симпатиясеннән һәм гаепләнүче коммунистларның фаш итүләреннән куркып, эшне ябык рәвештә үткәрергә карар бирде. Шулай итеп, коммунистларны „халык алдында гаепләү“ планы шунда ук җимерелде.

Франциянең язмышын хәл итүчеләрдә халык алдына чыгудан болай курку нәрсәдән килеп чыга соң? процесс уңае белән Франция компартиясе тарафыннан чыгарылган белдерүләрнең берсендә бу сорауга ачык җавап бирелә. Белдерүдә болай диелә:

„Карл Либкнехт тарафыннан Вильһельм II судьяләренә ташланган гаепләүне Франция хөкүмәтенә һәм аның судьяләренә карата кулланырга мөмкин“.

„Халыкны камалыш хәле богауларыннан һәм камчысыннан азат итегез. Халыкны монда яки теләсә кайда башка урында җыегыз, сугыш кырларыннан солдатларны җыегыз һәм миңа шушы җыелыш алдында, аларның суды алдында сөйләргә бирегез. Бер якта сез, суд, генерал—прокурор һәм генеральный штабтагы, хәрби министрлектәге шушы әфәнделәр булыгыз, ә икенче якта мин бер ялгызым булыйм, яки минем дусларымның берәрсе булсын. Күзләреннән ялган пәрдәсе алынгач, халыклар массасы кем ягына басар? Сезнең яккамы, яки минем яккамы? Мин җавапта һич тә шикләнмим. Бетсен хөкүмәт! Бетсен сугыш!“.

Франция хөкүмәте халыкка мөрәҗәгат итәргә теләми, ул революцион депутатларны халыкның присяжный утырышчылары судына бирми. Ул аларны үз чиновникларының—хәрби судьяләрнең баш-баштаклыгына тапшыра.

Үзенең мөрәҗәгатләренең берсендә компартия, депутатларга суд процессы—ул, миллион ярым сайлаучының вәкилләренә политик процесс дигән сүз дип күрсәтеп үтә. Чыннан да гаепләнүчеләр скәмиясендә утыручы депутатлар француз халкының чын вәкилләре икәнлеккә, ә процесс үзе Франция сугыш уты кабызучыларының халыкка каршы реакцион политикаларында аеручa оятсыз буыннарның берсе икәнлеккә ышану өчен бу депутатларның биографияләре һәм эшләре белән танышу гына да җитә.

Хәзер хәрби суд хөкем итә торган депутатлар исәбеннән 9 депутатны полиция тота алмаган. Азатлык һәм тынычлык өчен көрәшне дәвам иттерүче бу кешеләрне тота алмаганлыгына ачуланып, хөкүмәт аларны просто үзләренең коммунистик карашларына турылыклы булып калганнары өчен хыянәт итүдә гаепли. Бу депутатларга үлем куркынычы бар.

Бу депутатлар кемнәр?

Алар арасында Сена департаменты депутаты, Франция коммунистлар партиясенең генеральный секретаре Морис Торез бар. Бу кеше хезмәт ияләре күз алдында Француз халкы эшенә турылыклы булуны, бөтен дөнья хезмәт ияләре эшенә чын күңелдән бирелгән булуны гәүдәләндерә. Горняк улы һәм үзе дә горняк буларак Торез 19 яшеннән үк үзенең язмышын революцион хәрәкәт белән бәйли.

Кулга алуларга һәм эзәрлекләүләргә карамастан, Торез 20 ел буена армый-талмый партия эше алып бара.

Алар арасында шулай ук Сена департаменты депутаты, палатаның элекке вице-председателе, Франция коммунистлар партиясенең секретаре, хезмәт ияләре эшенә чын күңелдән бирелгән көрәшчеләрнең берсе Жак Дюкло да бар. Балта остасы улы, үзе икмәк пешерүче эшче буларак Дюкло да Франция эшчеләр хәрәкәтендә яштән үк актив катнашып килә. Үзенең революцион эше өчен күп тапкырлар судка бирелде һәм барсын бергә кушып алганда 30 елга төрмәгә хөкем ителде.

Шулай ук Сена һәм Уаза депутаты, Франция компартиясенең Үзәк Комитеты члены, „Юманите“ газетасында тышкы политика буенча үзенең үткен һәм ачык мәкаләләре белән атаклы булган күренекле журналист Габриэль Перигә дә үлем куркынычы бар.

Гаепләнүчеләр скәмиясендә компартия Үзәк Комитеты члены, депутат Флоримон Бонт та бар. Коммунист депутатлар кулга алынган вакытта октябрь башында полициянең эзәрлекләүләреннән кача алган Бонт парламентның ноябрь сессиясе вактында палатага килеп, сугыш уты кабызучыларның политикасын батырларча гаепләде. Реакционерлар төркеме, шул исәптән социалист депутатлар да, аны утырышлар залыннан сөйрәп чыгарып, бик каты кыйнадылар. Ул полиция кулына тапшырылды һәм шул вакыттан бирле төрмәдә утыра.

Аның белән бергә Парижның XIV нче районы депутаты, Франция коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты члены, Франциянең сугышка кадәр 800.000 члены булган металлистлар союзының генеральный секретаре Амбруаз Крауза да суд алдына килеп басты.

Бу исемлекне дәвам иттерергә мөмкин.

Франция халкының вәкилләре, үзләренең бөтен тормышларындагы кебек үк, судта да Франция хезмәт ияләренең интересларын батырларча яклауны һәм Франциянең хәзерге реакцион җитәкчеләрен фаш итүне дәвам иттерәләр. Депутат коммунистлар үзләрен Франциянең бөтен компартиясенең яклавын хис итәләр. Франция компартиясе демократик ирекләрне кысучыларны—соңгы процессны оештыручыларны үзенең ялкынлы өндәмәләрендә фаш итә һәм коммунист депутатларның көрәшләрен яхшы дип таба.

Коммунист депутатлар бөтен француз халкының һәм алдынгы прогрессив кешелек дөньясының интересларын кадерләүчеләрнең барсының да яклавын хис итәләр.

28 март.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 5 нче апрельдә, шулай ук 6 нчы апрельдә көндез һәм кич
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 5 нче апрельдә һәм иртәгә көндез
МАСКАРАД
6 нчы апрельдә кич В. Шкваркин әсәре
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
7 нче апрельдә Зур театр бинасында
ФАУСТ
9 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ИРЕК
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгаттә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, ху[illegible]стволы яңа фи[illegible] ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм ҖИР ПЛЕНДӘ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1352 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1260.